**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
________________

**КАРАР**
№ _________

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2024 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак Кодексының 14 статьясына таянып, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм бәянең иң чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы нигезендә гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт, күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән, шулай ук «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциячел булмаган партнерлыгының 2024 елның 1 яртыеллыгына Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында торак күчемсез мөлкәт базарын эксперт-аналитик тикшерүгә нигезләнеп һәм Россия Банкының бирелгән ипотека торак кредитлары буенча уртача үлчәүле процент ставкалары һәм сроклары күләме турындагы мәгълүматларын исәпкә алып физик затларга-резидентларга, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында Карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы чиге:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен-1 846 801,00 сум.;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 2 350 474,00 сум.;

1.1.3. өч кешелек гаилә өчен-3 022 038,00 сум.;

1.1.4. дүрт кешелек гаилә өчен-4 029 384,00 сум.;

1.1.5. биш кешелек гаилә өчен-5 036 730,00 сум.;

1.1.6. алты кешелек гаилә өчен-6 044 076,00 сум.;

1.1.7. җиде кешелек гаилә өчен-7 051 422,00 сум.;
1.1.8. сигез кешелек гаилә өчен-8 058 768,00 сум.;
1.1.9. тугыз кешелек гаилә өчен-9 066 114,00 сум.;
1.1.10. ун кешелек гаилә өчен-10 073 460,00 сум.;
1.1.11. унбер кешедән торган гаилә өчен – 11 080 806,00 сум.;
1.1.12. унике кешедән торган гаилә өчен – 12 088 152,00 сум.
1.2. граждан гаиләсенең һәр әгъзасына (ялгыз яшәүче граждан өчен)туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме бусагасы:
1.2.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен-33 526,00 сум.;
1.2.2. ике кешелек гаилә өчен-21 335,00 сум.;
1.2.3. өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 18 287,00 сум.
2. Әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 бүлекләрендә күрсәтелгән күрсәткечләрне социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда файдаланырга.
3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.Ф. Әхмәтшинга йөкләргә.

**Җитәкче**

**А.А. Гасыймов**